РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
Учаллинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального
района, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге

БАШЛЫГЫ

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«17» октябрь 2025ел. №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2025 елның 31 октябрендә 13 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2025 елның 31 октябрендә 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенын үткәрү урыны- Текмәле авылы, Ишкәй урамы, 15 нче йорт;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 17 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Үчәлле ав., Совет ур., 51 й.;Текмәле авылы, Ишкәй ур., 15 нче йорт;

- сайлау хокукына ия булган Текмәле торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Текмәле торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)

ӘЙЕ КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет ур., 51 йорт; Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Текмәле авылы, Ишкәй ур., 15 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aznakaevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина